**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге составына керүче **Түбән Кәминкә** авылы торак пунктында

**30 октябрь 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Түбән Кәминкә авыл җирлегенең Түбән Кәминкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **Түбән Кәминкә** торак пунктында **торак пунктның территориясен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, тракторга отвал сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Түбән Кәминкә торак пунктында урам яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру)**;**
- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Түбән Кәминкә торак пунктындагы суүткәргеч челтәре скважиналарына насослар сатып алу).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков